# Хәсән Туфан
# (1900- 1981)



Татар совет поэзиясе классигы Хәсән Туфан (Хәсән Фәхри улы Туфан) 1900 елның 27 ноябрендә (яңа стиль белән 9 декабрьдә) элекке Казан губернасы Чистай өязе (хәзерге Татарстан ССРның Аксубай районы) Иске Кармәт авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа.

Булачак шагыйрь башлангыч белемне әтисеннән ала, үзлегеннән дә укый, соңрак авыл мәктәбенә йөри. 1914 елның язында ул Тобол губернасының Ахман авылында урнашкан абыйлары янына барып, бакыр колчеданы руднигында эшли. Шул елны аны абыйлары Уфаның «Галия» мәдрәсәсенә укырга җибәрәләр. Анда ул Г. Ибраһимовтан әдәбият дәресләре ала, Ш. Бабич оештырган әдәби түгәрәккә йөри, С. Рәмиев, М. Гафури, С. Сүнчәләйләр белән аралаша.

Җәйге каникул көннәрендә Урал рудникларында шахтер, сәгать төзәтүче, Лысьва металлургия заводында токарь булып эшләп, кышлык акча юнәтә. 1917 елның февраль, аннары Октябрь көннәрен ул Лысьва заводында каршылый.

Х. Туфан әсәрләре беренче тапкыр 1924 елда басылып чыга. Бу елларда ул шул чорда татар поэзиясе ирешкән уңышларның иң күренекле үрнәкләре булырлык шигъри әсәрләрен яза.

1928 елда Туфан җәяүләп Кавказ һәм Урта Азия якларына ике еллык сәяхәткә чыгып китә. Казанга әйләнеп кайткач, 1930 — 1934 елларда Татарстан радиокомитетында әдәби һәм музыкаль тапшырулар редакторы була. 1934 елда шагыйрь СССР Язучылар союзына член итеп алына.

1937 елга чаклы «Совет әдәбияты» (хәзер «Казан утлары») журналының жавап-лы секретаре булып эшли. 1940—1956 елларда ул хаксызга төрмәгә утыртылуы, сөргенгә сөрелүе аркасында әдәбияттан аерылып тора, 1956 елның җәенә яңадан Казанга кайта һәм аның иҗаты тагын бөтен таланты белән ачылып китә, шагыйрь гомеренең соңгы көненә кадәр (ул 1981 елның 10 июнендә Казанда вафат булды) иҗади хезмәтен туктатмый, яңадан-яңа әсәрләр язуын дәвам итә.

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре һәм «Сайланма әсәрләр» (Казан, 1964) китабы өчен Хәсән Туфанга Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге. Дәүләт премиясе бирелде.

Хәсән Туфан иҗаты татар совет поэзиясе тарихында тирән эз калдырды, аның әсәрләре татар әдәбияты хәзинәсендә әһәмиятле урын тоталар.

# Әсәрләре:

«Мин ышанмыйм әле үлүеңә...»
«Столовойның кызлары...»
«Урамнарны ялгыз ураганда...»
Агыла да болыт агыла
Ак каен
Гөлләр инде яфрак яралар
Зәңгәр күз
Илдә ниләр бар икән?
Кайсыгызның кулы җылы?
Козырь туз
Күлмәгең талда
Мөгезендә чылбыр өзеге

